ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) икенче өлештә «оешмалар хезмәткәрләре» сүзләрен «оешмаларда эшләүче яисә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «оешмалар хезмәткәрләрен» сүзләрен «оешмаларда эшләүче яисә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларны» сүзләренә, «һөнәри белем бирү программалары» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем бирү программалары (янгын-техник минимум программалары)» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлештә «оешмалар хезмәткәрләрен» сүзләрен «оешмаларда эшләүче яисә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 64-ТРЗ